**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**
**КАРАРЫ**

14 июнь 2019 ел **№ 180** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының 2008 елның 02 июнендәге «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмә турында»гы 155 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының 2019 елның 14 мартындагы 214 санлы хатын караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2006 елның 6 октябрендәге 131 санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Теләче муниципаль районы Советының 2008 елның 02 июнендәге «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмә турында»гы 155 санлы карарына (2015 елның 29.12 № 32, 2016 елның 15.11 № 69 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 2 бүлектә:

- 1.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

« - Теләче муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы көрәштә үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлдәге законнар нигезендә катнашу»;

« - җәмгыятьтә коррупцион гадәтләргә түзеп тормаучанлыкны формалаштыру»

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов